| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОИШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ИШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

Яңа Ишле авылы

РЕШЕНИЕ КАРАР

13 марта 2025 ел № 55/1

"Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында»карар проекты турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Уставының 32 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә, Татар транспорт прокуратурасының 25.02.2025 ел №23/1-2-2025 протестын, Чүпрәле районы прокуратурасының 06.03.2025ел № 02-08-02-2025 протестын исәпкә алып Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба – текст буенча-кагыйдәләр), Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Советының 20.09.2017 ел, № 19/1 карары (Советның 2018 елның 21.03.2018ел № 26/1, 29.10.2021 ел, №13/1,06.04.2022 ел №20/1, 29.08.2022 № 23/2 карарлары белән расланган үзгәрешләр белән), кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

3. Әлеге карарны торак пунктлар территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Яңа Ишле авылы, Совет урамы, 24 нче йорт, мәдзният бинасы, Иске Ишле авылы, Үзәк урамы, 16 нче йорт, мәктәп бинасы Яңа Кәкерле авылы Ленин урамы 33 йорт мәктәп бинасында һәм Яңа Ишле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 15 апрелендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Чүпрәле районы, Яңа Ишле авылы, Совет урамы, 24 йорт Яңа Ишле авылы мәдәният йортында билгеләргә,.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлегендә гавами тыңлауларын (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июнендәге 11/2 номерлы карары белән расланган (16.12.2022 №27/3 редакциясендә), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Нигезләмә нигезендә уздырыла.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советының 20.12.2013 № 35/3 карары белән расланган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырылган Тәртип нигезендә үткәрелә.

6. Әлеге проект буенча гражданнарның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре 2025 нче елның 14 апреленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Чүпрәле районы, Яңа Ишле авылы, Совет урамы, 24 нче йорт.

7. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советына карауга кертергә тиеш

8. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә керген нигезләмәләрдән тыш, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми халыкка хәбәр итү һәм урнаштыру көнендә үз көченә керә.

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле
муниципаль районы
Яңа Ишле
авыл җирлеге
Советының 13.03.2025 ел №55/1 карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр

1) **35 пунктның 35.11 пунктчасында** «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга.;

2) **37 пунктның 5 пунктчасында** «һәм тимер юл " сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 65, 66, 67 пунктларда «(тимер юл)» сүзен төшереп калдырырга.

4) **185 пунктны** төшереп калдырырга.

Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мухаметзянов